КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 9 апрель г.Казань № 211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 ел, 31 декабрь, 920 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 август, 712 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 27 август, 625 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1317 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 818 нче; 2021 ел, 13 декабрь, 1214 нче; 2022 ел, 18 апрель, 361 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документлар әйләнешеннең бердәм ведомствоара системасы турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктында «Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләренраслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә

алуны һәм алардан файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 31 июлендәге 77 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасының «Контроль» модуле эшләве тәртибенә 5 нче кушымтаның I бүлегендәге дүртенче абзацында «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 1014 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин